**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет «Тумутукского сельского поселения» Азнакаевского муниципального района**

ул. Тельмана, д.62Б, с. Тумутук
Азнакаевского муниципального района
423316, Тел. (885592) 3-43-42

Электронная почта: Tumut.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Тымытык авыл жирлеге» башкарма комитеты**

Азнакай муниципаль районы, Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б
423316, Тел. (885592) 3-43-42

Электрон почта: Tumut.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» октябрь 2021 ел № 29

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 23 номерлы «Агачларны кисү, кронлау, агачлар, куаклар утырту һәм кучереп утырту, газон җыю өчен рөхсәт бирү буенча административ регламентны раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 23 номерлы «Агачларны кисү, кронлау, агачлар, куаклар утырту һәм күчереп утырту, газон җыю өчен рөхсәт бирү буенча административ регламентны раслау турында» карары белән расланган, агачларны кисү, кронлау, агачлар, куаклар утырту һәм күчереп утырту, газон җыю өчен рөхсәт бирү буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында «агачларның, куакларның торышы турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3 пунктын 2.5.4 пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның башкарма комитеты яисә җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4 пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның башкарма комитеты яисә җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.1 пунктының 6, 11 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «муниципаль районның җирле үзидарә органы яисә төзелгән килешү нигезендә башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.6.3 пунктында «башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында «гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә аеруча кирәк булган (зыян килгән) яшел утыртмаларны сүтү кирәклеген расламау» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында «(авария-торгызу эшләрен башкаруга яисә яшел утыртмаларны җимерүгә бәйле очраклардан тыш (агачның, зыян килгән агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 2.8.4 пунктында «2 нче кушымтада» сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга.»;

1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында «, шулай ук авария-торгызу эшләрен уздыру яисә яшел утыртмаларны җимерү өчен (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәт алган очракта)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3 пунктын төшереп калдырырга;

1.12. 3.5.5 пунктында «; авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә яшел утыртмаларны җимергәндә муниципаль хезмәт алуны сорап мөрәҗәгать иткән очракта (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) - ике эш көнен төшереп калдырырга» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. Регламентка 2 нче кушымтада «Зыян килгән агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Тымытык авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) игълан итәргә, шулай ук Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Башлык Э.Х.Гыйләҗева